**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.08.2024 **Чирмешән авылы** № 280

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Чирмешән муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 мартындагы 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 мартындагы 288 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Чирмешән муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 мартындагы 92 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15.2 пунктның 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм куллануга даими әзерлек халәтендә тоту»;

1.2 15.5 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә «15.5. Яктылык һәм маскировканың башка төрләре буенча:

маскировкаланырга тиешле объектлар исемлеген билгеләү;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә кертелгән территорияләрне комплексլы маскировкалауны гамәлгә ашыру планнарын эшләү;

яктылык һәм маскировканың башка төрләре буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын билгеләү буенча файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту һәм булдыру;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы төркемнәренә кертелгән территорияләрнең демаскировкалау билгеләрен киметү буенча инженер-техник чаралар үткәрү.».

1.3. 16.2 пунктның 3 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов